Иҗатында - тормыш чынбарлыгы

Кемнәрдер әдәбиятка мәктәп чорыннан килеп керәләр дә, каләмнәрен кулдан төшерми иҗат итәләр. Берәүләр олыгаеп, иҗатта да, тормышта да саллы тәҗрибә туплап килә. Әсгать Салахов шундыйлардан. Әдәбият елы буларак игълан ителгән 2015 елның январь аенда күренекле җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр шәхес, публицист, прозаик Әсгать Сахап улы Салахов үзенең 80 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтте.

Узган атнада Әлмәт сәүдә - икътисад техникумының актлар залында язучы белән "Яшәгән саен, яшисе килә" дип исемләнгән очрашу - чын күңелдән сөйләшү, хатирәләләр уртаклашу, җыр,биюләр белән үрелеп барган күркәм бер чара булып узды.

Көчле алкышлар астында сәхнәгә күтәрелгән язучының әдәбиятка, журналистикага керткән өлеше, чыннан да, бәяләп бетергесез. Очрашуны башлап Әлмәт язучылар берлеге рәисе Рәфкать Шаһиев нәкъ менә шул турыда сөйләде.

Күпләрне гаҗәпләндереп һәм сокландырып, туксанынчы еллар ахырында һәм гасыр башында республика вакытлы матбугатында Ә. Салах хикәяләре һәм повестьлары, әдәби очерклары, публицистик язмалары күренә башлый. Республикабызның төрле нәшриятларында бер-бер артлы китаплары дөнья күрә. Язучы әдәбият мәйданында исә үзенең күпләрне таң калдырган көчле повестьлары белән танылa. Әсгать Салах яңадан - яңа әсәрләр иҗат итүен дәвам итә. Ул - "Аккан сулар" дип исемләнгән автобиографик әсәр, балалар әдәбиятын баеткан "Балыкчы малайлар" хикәясе, туган - төбәк тарихын яктырткан "Бараҗ токымы" китабы, берничә повестьне эченә алган "Каеннар юлы" китабы һәм кешелек дөньясын тетрәткән Чернобыль вакыйгасын яктыркан "Соңгы вальс" әсәрләре авторы.

Әсгать Салахның язучы буларак осталыгы турында сөйләгәндә, әсәрләрендәге тел-стиль камиллеге, чагыштырулар, сынландырулар оригинальлеге, халык авыз иҗаты җәүһәрләреннән, җирле сөйләмнән, гореф - гадәт һәм ырым - йолаларны сурәтләүне отышлы файдалануын да әйтеп үтәргә кирәк.

Ул бүгенге көн прозасында актив һәм йотлыгып эшләүче каләм ияләренең берсе. Язучы иҗатының әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләре тарафыннан төрле яклап тикшерелгән әсәре - "Соңгы вальс". Галимнәр әсәрне XX гасыр ахыры татар әдәбиятында үсеп килүче яңа романтизм агымына кертәләр.

Әсгать Салаховның яшьләр, китап укучылар белән уртаклашыр истәлекләре дә бихисап булып чыкты. Автор үзе билгеләп узганча, аның әсәрләрендәге бер генә герой, бер генә персонаж да уйдырма түгел, алар тормыштан,чынбарлыктан алынган авылдашлар, күршеләр, дуслар, хезмәттәшләр. "Балыкчы малайлар", "Бараҗ токымы" әсәрләренең язылу тарихы да һәркемгә кызыклы булды.

Мөхтәрәм язучыны иҗат бәйрәме, узган юбилее белән тәбрикләргә мәдәният идарәсе җитәкчесе урынбасары Эльмира Хәсәнова да килгән иде. Ул башкарма комитет, Совет исеменнән юбилярга Мактау грамотасы, китапларын алырга 10 мең сумлык сертификат тапшырды.

Агымдагы елда 85 яшен билгеләп узучы Әлмәт районында беренче татар матбугатына нигез салучы, аны оештыручы буларак та Әсгать Сахаповичка хөрмәтебез зур. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә сәхнәгә менеп, юбилярга тәбрикләүләрен җиткерделәр. "Хәзинә" газетасы мөхәррире Илшат Мингәрәев язучыга "Татнефть" ААҖ, "Рухият" рухи -яңарыш фонды исеменнән бүләкләр тапшырды.

Очрашуга килгән мөхтәрәм кунаклар - Россия эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлек начальнигы, полиция полковнигы Дамир Гарипов, ӘМР ның мактаулы гражданины, нефтьче- ветеран Госман Камалов, язучыларның һәрберсе Әсгать Салаховның язучы, журналист, милләтпәрвәр шәхес буларак башкарган хезмәтләренә тукталып, аның иҗатына карата булган ихтирамнарын белдерделәр. Чара студентлар тарафыннан әзерләнгән чыгышлар, Валентина Исламова башкаруындагы җырлар белән бизәлде.

Бәйрәмне йомгаклап, Әсгать Салахов чараны оештыручы Әлмәт язучылар берлегенә, Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты ректоры, Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Ильяс Салаховка, әдәбият яратучы дусларына, иҗатташларына олы рәхмәтен белдерде.

P.S. *Гомумән, Әсгать Салаховның иҗаты беркемне дә кабатламый торган, яңа романтизм һәм романтик реализм юнәлешендә үзенчәлекле бер катлам тәшкил итүе белән үзенчәлекле. "Альметьевский вестник" газетасы мөхәррияте, газета укучылар исеменнән юбилярны иҗат бәйрәме белән тәбрик итә, язучыдан яңадан-яңа әсәрләр көтеп кала.*

Фәрдия ХӘСӘНОВА

"Шигъри чишмә"нең сулары мулдан

Татар дөньясына бөек Тукайны бүләк иткән апрель аенда республикабызның һәрбер төбәгендә шигырь бәйрәмнәре уздырыла. Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәрендә дә әлеге матур традиция күп еллар дәвам итә. Балаларны туган телебезнең аһәңен, тирәнлеген аңларга этәргеч биргән, үз милләтенең горур кызлары, уллары булырга өндәгән әлеге чаралар әти-әниләр, тәрбиячеләр, укытучылар тарафыннан да бик хуплап каршы алына.

Быелгы чара "Шигъри чишмә" дигән исем белән Балалар һәм яшүсмерләр иҗаты үзәгендә узды.

Шигырь бәйрәмен мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча урынбасары Сирина Җиһаншина ачып җибәрде. Ул мәгариф идарәсе җитәкчесе Рафаэль Ганиевның котлауларын җиткереп, катнашучыларга уңышлар теләде.

ТР Язучылар союзының Әлмәт бүлеге рәисе Рәфкать Шаһиев агымдагы елның Әдәбият елы, Бөек Җиңүнең 70, Әлмәт районының 85 еллыгы кебек олы юбилейларга бай булуын ассызыклап узды. Балаларның әдәбиятны, шигъриятне яратып, укып үсүләрен теләде.

Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге, каршысында эшләп килүче "Ак калфак" татар хатын-кызлары оешмасы , "Альметьевский вестник" газетасы баш мөхәррире Ландыш Зарипова үзенең чыгышында билгеләп узганча, район һәм шәһәребезнең мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә сабыйларны татар теленә өйрәтү, тәрбияләү, бу эшкә әти-әниләрне тарту, кызыксындыру юнәлешендә искиткеч зур эшләр башкарыла. Укучыларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә карата игътибарлы караш, шуларның бөтенесен берләштергән әхлак тәрбиясе буенча мәктәпләрдә максатчан эшчәнек алып барылу да район хакимияте, мәгариф идарәсе, иҗтимагый оешмаларның уртак тырышлык нәтиҗәсе дип бәяләде ул.

Бәйрәм 44 нче балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр чыгышы белән башланып китте. Аннары алып баручылар мәртәбәле жюри әгъзалары белән таныштырдылар. Сәхнәгә бер- бер артлы чыккан нәниләрнең сәнгатьле итеп, саф татар телендә яңгыраткан шигырьләрне тыңлап күңелләр хозурланды.

Төштән соң бәйгенең икенче өлеше башланып, осталыкта мәктәп укучылары көч сынашты.

"Шигъри чишмә" бәйгесендә барлыгы 147 бала(70- е мәктәпләрдән, 77 се - балалар бакчаларыннан) катнашты.

Шәһәр мәктәпләренең 5-6 сыйныф укучылары арасында урыннар түбәндәгечә бүленде:

I урын - Мансурова Алсу (Р.Фәхреддин исемендәге 1 нче гимназия.)

II урын - Хафизов Айнур (25 нче мәктәп)

III урын - Газизов Рөстәм (10 нчы мәктәп)

1-4 сыйныфлар

I урын - Миннәхмәтова Азалия (20 мәктәп)

II урын - Миннебаева Элина(Р.Фәхреддин исемендәге 1 нче гимназия)

III урын - Кирамов Шамил (1 нче мәктәп)

Авыл мәктәпләре арасында

I урын - Калимуллина Гүзәл (Иске Михайловка авылы мәктәбе)

II урын - Салахов Илсаф (Мәмәт мәктәбе)

III урын - Әхмәтҗанов Алмаз (Югары Мактама мәктәбе)

Балалар бакчалары :

I урын - 9 нчы бакчадан Саттаров Вил

II урын - 14 нче бакчадан Гусейнов Булат

III урын - Колшәрип авылы балалар бакчасыннан Гыйниятуллина Камилла.

Шунысы игътибарга лаек, бәйрәмдә катнашучы бер генә бала да чарадан бүләксез китмәде. "Шигъри чишмә" не оештыручылар хәйрия ярдәме күрсәткән, балаларга төрле бүләкләр өләшү мөмкинлеге биргән Яр Чаллы шәһәренең "Уенчыклар" кибетенә, җиңүчеләрне татлы күчтәнәчләре белән сөендергән "Агат" сәүдә йортына, билетлар белән тәэмин иткән "Старсинема" кинотеатрына, "Макдональдс" ресторанына, "Арт-Диалог" компаниясенә олы рәхмәтләрен җиткерәләр.

Фәрдия ХӘСӘНОВА